**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Югары Чегодай,
Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино
торак пунктында (ларында) гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 13,14,15,18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде киләсе мәсьәлә буенча:

1. «2022 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Үтәмеш, Югары Чегодай, Урманасты Үтәмеш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Иске Үтәмеш, Югары Чегодай, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- су башняларын, скважиналарны, Урманасты Үтәмеш авылында «Мәнди», Иске Үтәмеш авылында «Мәликә», «Атау», Югары Чегодай авылында «Әчеле» чишмәләрен реконструкцияләү һәм ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас

частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Урманасты Үтәмеш торак пунктында балалар уен мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү дәүләт программалары буенча катнашу өчен Иске Үтәмеш авыл җирлегендә авыл территорияләрен үстерү проект-смета документларын әзерләү һәм түләү чыгымнары.

2. «2022 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Проект-смета документациясен эшләү, җир кишәрлекләрен ызанлау, Иске Сережкино авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 633 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 389 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 389 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча:

«2022 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- су башняларын, скважиналарны, Урманасты Үтәмеш авылында «Мәнди», Иске Үтәмеш авылында «Мәликә», «Атау», Югары Чегодай авылында «Әчеле» чишмәләрен реконструкцияләү һәм ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Урманасты Үтәмеш торак пунктында балалар уен мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү дәүләт программалары буенча катнашу өчен Иске Үтәмеш авыл җирлегендә авыл территорияләрен үстерү проект-смета документларын әзерләү һәм түләү чыгымнары.

«2022 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Коралллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- проект-смета документациясен эшләү, җир кишәрлекләрен ызанлау, Иске Сережкино авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу – карар кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Югары Чегодай авылы, Совет урамы, 25А йорт, Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 54 нче йорт, Урманасты Үтәмеш авылы, Совет урамы, 12А йорт, Иске Сережкино авылы, Степная урамы, 7а йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырып чыгарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов